**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районынын Иске Имән авыл жирлеге**

**КАРАР**
**05.04.2023**

**КАРАР**
**№75**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман районы Прокуратурасы 2023 елның 02 мартындагы 02-01-21/2023 номерлы мәгълүмат нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Иске Имән авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 3 пунктына «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 18 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм http:/ www.sarmanovo.tatar.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова